**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 20 декабрь № 958

г. Казань

Татарстан Республикасы дәүләт торак фонды, муниципаль торак фонды, шулай ук хосусый торак фонды составына керә торган торак урыннарга мөнәсәбәтле, инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып, инвалидларның торак урыннарын уңайлаштыру чараларын яраштыру буенча Татарстан Республикасының вәкаләтле башкарма хакимият органын билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 12 һәм 15 статьялары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып, күпфатирлы йорттагы торак урыннарны һәм уртак мөлкәтне уңайлаштыру чаралары турында» 2016 ел, 9 июль, 649 нчы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгын (алга таба – Министрлык) Татарстан Республикасы дәүләт торак фонды, муниципаль торак фонды, шулай ук хосусый торак фонды составына керә торган торак урыннарга мөнәсәбәтле, инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып, инвалидларның торак урыннарын уңайлаштыру чараларын яраштыру буенча Татарстан Республикасының вәкаләтле башкарма хакимият органы итеп билгеләргә.

2. Инвалидларның ихтыяҗларын һәм инвалидлар өчен файдалана алу шартларын тәэмин итүне исәпкә алып, инвалидларның торак урыннарын һәм Татарстан Республикасы торак фонды составына керә торган инвалидлар яши торган күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне уңайлаштыру буенча чаралар планын (карарга теркәлә) расларга.

3. Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

1) инвалидларның ихтыяҗларын һәм инвалидлар өчен файдалана алу шартларын тәэмин итүне исәпкә алып уңайлаштыру максатларында, инвалидларның

торак урыннарын һәм инвалидлар яши торган күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне тикшерү буенча муниципаль комиссияләр (алга таба – муниципаль комиссияләр) төзергә, аларның составларын һәм муниципаль комиссияләрнең эш тәртибен расларга;

2) инвалидларның ихтыяҗларын һәм инвалидлар өчен файдалана алу шартларын тәэмин итүне исәпкә алып, инвалидларның торак урыннарын һәм муниципаль торак фонды, шулай ук хосусый торак фонды составына керә торган инвалидлар яши торган күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне уңайлаштыру буенча чаралар планнарын (алга таба – чаралар планы) расларга;

3) муниципаль комиссияләр һәм расланган чаралар планнары турындагы мәгълүматны Министрлык адресына җибәрергә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\958.doc

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 20 декабрь, 958 нче карары белән расланды

Инвалидларның ихтыяҗларын һәм инвалидлар өчен файдалана алу шартларын тәэмин итүне исәпкә алып, инвалидларның торак урыннарын һәм Татарстан Республикасы торак фонды составына керә торган инвалидлар яши торган күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне уңайлаштыру буенча чаралар планы

| Т/с | Чара | Чараны үтәү вакыты | Җаваплы үтәүчеләр |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Инвалидларның ихтыяҗларын һәм инвалидлар өчен файдалана алу шартларын тәэмин итүне исәпкә алып уңайлаштыру максатларында, Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булган торак урыннар исемлеген әзерләү һәм инвалидларның торак урыннарын һәм инвалидлар яши торган күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне тикшерү буенча региональ ведомстволара комиссиягә (алга таба – региональ комиссия) җибәрү. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы күрсәтелгән торак урыннар исемлеге белән тапшырган инвалидлар исемлегенә чагыштырма анализ үткәрү | 2016 елның декабре | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы |
| 2. | Инвалидлар исемлеген әзерләү һәм региональ комиссиягә җибәрү | 2016 елның декабре | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы |
| 3. | Әлеге Планның 1 һәм 2 нче пунктларында күрсәтелгән документларны карап тикшерү һәм инвалидларның торак урыннары һәм Татарстан Республикасы торак фонды | 2017 елның гыйнвары | региональ комиссия |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | составына керә торган инвалидлар яши торган күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәт реестрын төзү | | |
| 4. | Региональ комиссия тарафыннан Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре актылыгында инвалидларның дәүләт милкендә булган торак урыннарын һәм инвалидлар яши торган күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне тикшерү схемасын (тәртибен) эшләү һәм раслау | 2017 елның гыйнвары | региональ комиссия |
| 5. | Тикшерү графигы (йомгаклары) буенча фикер алышып, утырыш үткәрү һәм региональ комиссия эше буенча рекомендацияләр эшләү | квартал саен | региональ комиссия |
| 6. | Торак йортның тотып торучы конструкцияләренә өстәмә тикшерүләр, сынаулар үткәрергә кирәк булганда, инвалидның торак урынына, инвалид яши торган күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәткә визуаль, техник тикшерү үткәрү;<br>торак урынны уңайлаштыруга мөнәсәбәтле гражданның аерым бер ихтыяҗларын билгеләү максатларында, торак урында яши торган инвалид дип танылган граждан белән әңгәмә үткәрү;<br>инвалидның ихтыяҗларын һәм инвалид өчен файдалана алу шартларын тәэмин итүне исәпкә алып, инвалидның торак урынын һәм инвалид яши торган күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәтне уңайлаштыру ихтыяҗын һәм мөмкинлеген билгеләү | 2017 елның феврале – марты | региональ комиссия |
| 7. | Инвалидның ихтыяҗларын һәм инвалид өчен файдалана алу шартларын тәэмин итүне исәпкә алып уңайлаштыру максатларында, инвалидның торак урынына һәм инвалид яши торган күпфатирлы | Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министр- | региональ комиссия |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | йорттагы уртак мөлкәткә тикшерү актын (алга таба – тикшерү акты) әзерләү | лыгы тикшерү акты формасын раслаган көннән соң 3 ай эчендә | |
| 8. | Инвалидның ихтыяҗларын һәм инвалид өчен файдалана алу шартларын тәэмин итүне исәпкә алып, инвалидның торак урынын һәм (яки) инвалид яши торган күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәтне уңайлаштыру максат-ларында, күпфатирлы йортны (йортның бер өлешен) төзекләндерү яки капиталь ремонтлауның икътисадый яктан максатка ярашлы булуына тикшерү үткәрү турында карар кабул итү (тикшерү актында күпфатирлы йортны (йортның бер өлешен) төзекләндерү яки капиталь ремонтлау юлы белән аның гамәлдәге тотып торучы һәм киртәләүче конструкцияләрен үз-гәртмичә, инвалидның ихтыяҗ-ларын һәм инвалид өчен файдалана алу шартларын тәэмин итүне исәпкә алып, инвалидның торак урынын һәм (яки) инвалид яши торган күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәтне уңайлаштыру мөмкин булмау турында нәтиҗә булган очракта) | тикшерү актын төзегәннән соң 3 ай эчендә | региональ комиссия |
| 9. | Инвалидның ихтыяҗларын һәм инвалид өчен файдалана алу шартларын тәэмин итүне исәпкә алып, инвалидның торак урынын һәм (яки) инвалид яши торган күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәтне уңайлаштыру максат-ларында, күпфатирлы йортны (йортның бер өлешен) төзекләндерү яки капиталь ремонтлауның икътисадый яктан максатка ярашлы булуына тикшерү үткәрү | Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-ком-муналь хуҗа-лык министр-лыгы тикшерү үткәрү кагый-дәләрен рас-лаган көннән соң 3 ай эчендә | Татарстан Республи-касы Төзелеш, архи-тектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, регио-наль комиссия |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 10. | Инвалидның ихтыяҗларын һәм инвалид өчен файдалана алу шартларын тәэмин итүне исәпкә алып, инвалидның торак урынын һәм (яки) инвалид яши торган күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәтне уңайлаштыру максат-ларында, инвалид яши торган күпфатирлы йортны (йортның бер өлешен) төзекләндерү яки капиталь ремонтлауның икътисадый яктан максатка ярашлы булуы яки булмавы турында карар кабул итү | Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы карар формасын раслаган көннән соң 5 ай эчендә | региональ комиссия |
| 11. | Инвалидның ихтыяҗларын һәм инвалид өчен файдалана алу шартларын тәэмин итүне исәпкә алып, инвалидның торак урынын һәм инвалид яши торган күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәтне уңайлаштыру мөмкинлеге турында яки мондый мөмкинлек булмау хакында бәяләмә кабул итү һәм әлеге бәяләмәне Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына җибәрү | Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы бәяләмә формасын раслаган көннән соң 5 ай эчендә | региональ комиссия |

---